# КАРАР

**“22” ноябрь 2019 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 21 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 90 яшьтән узган гражданнардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Г.Камал урамы, 13 йорттан 16 йортка кадәр юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш түшәү;
- урам утларын ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Зур Кызыл урамы, 24а йортыннан Муса Җәлил урамы, 26 йортка кадәр суүткәргеч системасы торбалары урнаштыру;
- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- материаллар сатып алып, зират коймасын ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 150 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 77 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 75 кеше тавыш бирде;

“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә Алан авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Югары Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 90 яшьтән узган гражданнардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Г.Камал урамы, 13 йорттан 16 йортка кадәр юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш түшәү;

- урам утларын ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- Зур Кызыл урамы, 24а йортыннан Муса Җәлил урамы, 26 йортка кадәр суүткәргеч системасы торбалары урнаштыру;

- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;

- материаллар сатып алып, зират коймасын ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ» - 75 “КАРШЫ“-2

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Сарай-Чокырча авылы, Зур Кызыл урамы, 21 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина